ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

Ямбакты авыл җирлегенең Ямбакты торак пунктында

2022 елда үзара салым кертү турында

2021 елның 10 декабре, № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлегенең Ямбакты авылында гражданнар җыены

Карар:

1.2022 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзсалым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә эшләрне башкару өчен тотарга:

-Ямбакты авылында коры агач-чүп үләннәре, куаклар кисү (килешү буенча эш өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- триммерларны һәм бензопилларны агымдагы карап тоту һәм ремонтлау (ягулык-майлау материаллары, триммерлар һәм бензопилалар өчен запас частьләр сатып алу);

- Ямбакты авылындагы энергия саклаучы лампаларны, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, урнаштыру ( килешү буенча эш өчен түләү);
- Ямбакты авылында юлларны кардан чистарту (МТЗ-82 тракторына ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Ямбакты авылында Сабантуй , өлкәннәр көне,һәм башка бәйрәмнәрне оештыру һәм үткәрү ( бүләкләр, сувенирлар сатып алу);

- Ямбакты т. п. чүплекләрендәге чүпләрне эттерү (килешү буенча эшләр өчен түләү, транспорт хезмәтләре өчен түләү);

- Ямбакты т.п. зираты өчен бензоперфатор сатып алу;

3. җыен нәтиҗәләрен Ямбакты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:// spasskiy.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга

Халык җыенында рәислек итүче,

Ямбакты авыл җирлеге башлыгы: И.Ә. Галәветдинов

СОВЕТ ЯМБУХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ